КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 28 март г.Казань № 182

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «М.Җәлил исемендәге Республика премиясе турында» 1997 ел, 27 февраль, 175 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «М.Җәлил исемендәге Республика премиясе турында» 1997 ел, 27 июль, 175 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 ел, 11 март, 149 нчы, 2015 ел, 16 февраль, 95 нче, 2019 ел, 8 февраль, 83 нче, 2020 ел, 30 декабрь, 1254 нче, 2022 ел, 29 сентябрь, 1048 нче, 2023 ел, 15 февраль, 149 нчы, 2023 ел, 29 март, 373 нче, 2023 ел, 16 июнь, 723 нче, 2024 ел, 12 сентябрь, 772 нче, 2024 ел, 27 ноябрь, 1064 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган М.Җәлил исемендәге Республика премиясе турындагы нигезләмәдә:

3 пунктта «сентябрьнең икенче декадасында» сүзләрен «августның икенче ункөнлегендә» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктта:

беренче абзацта «әсәрләр һәм эшләр» сүзләрен «әлеге Нигезләмәнең 1 пунктында күрсәтелгән әсәрләр яисә эшләр (алга таба – әсәрләр яисә эшләр)» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацта «Әсәрләр һәм» сүзләрен «Әсәрләр яисә» сүзләренә алмаштырырга, «эшләр» сүзен «әсәрләр яисә эшләр» сүзләренә алмаштырырга;

6 пунктта «2 тапкырдан да артык булмаган» сүзләрен «ике тапкырдан да күбрәк булмаган» сүзләренә алмаштырырга, «2 һәм аннан да күбрәк эшләр өчен» сүзләрен «ике һәм аннан да күбрәк әсәр яисә эш өчен» сүзләренә алмаштырырга;

7 пунктта «Эшләр һәм материаллар» сүзләрен «Әсәрләр яисә эшләр» сүзләренә, «19 декабрьгә кадәр» сүзләрен «30 ноябрьгә кадәр» сүзләренә алмаштырырга, «эш мәгълүматлары» сүзләрен «әсәрләр яисә эшләр» сүзләренә алмаштырырга;

71 пунктта «авторлык эшләре һәм материаллары» сүзләрен «әсәрләре яисә эшләре» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 72 - 74 пунктлар өстәргә:

«72. М.Җәлил исемендәге Республика премиясен алуга тәкъдим ителгән әсәрләр һәм эшләр конкурс игълан ителгән елның 20 декабрьдән 31 декабрьгә кадәр карала һәм бәяләнә.

73. М.Җәлил исемендәге Республика премиясен алуга тәкъдим ителгән әсәрләр яисә эшләр әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән конкурс шартларына һәм таләпләренә туры килмәсә һәм (яисә) тулы булмаган һәм (яисә) дөрес булмаган белешмәләр булса, конкурска кертелми.

Әсәрләрне яисә эшләрне конкурска кертүдән баш тарту турында М.Җәлил исемендәге Республика премиясен бирү комитеты дәгъва итүчегә әлеге Нигезләмәнең 72 пунктында күрсәтелгән әсәрләрне яисә эшләрне карау һәм бәяләү срогы тәмамланган көннән башлап 15 көн эчендә utalents.ru сайтында һәм (яисә) почта элемтәсе аша хәбәр итә.

74. М.Җәлил исемендәге Республика премиясен алуга тәкъдим ителгән әсәрләрне яисә эшләрне сайлап алу, М.Җәлил исемендәге Республика премиясен бирү турында карар кабул итү һәм аны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына раслауга тәкъдим итү конкурс игълан ителгән елдан соң килә торган елның 1 гыйнварыннан 31 гыйнварына кадәр гамәлгә ашырыла.»;

8 пунктта:

беренче абзацта «Эшләр һәм фәнни-техник эшләнмәләр» сүзләрен «Әсәрләр яисә эшләр» сүзләренә алмаштырырга, «эшләр» сүзен «әсәрләр яисә эшләр» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацта «әсәрләрен һәм» сүзләрен «әсәрләрен яисә» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «әсәрләрен һәм» сүзләрен «әсәрләрен яисә» сүзләренә алмаштырырга;

12 пунктта «конкурс эшләре» сүзләрен «әсәрләре яисә эшләре» сүзләренә алмаштырырга;

13 пунктның беренче абзацында «әсәрләрен һәм» сүзләрен «әсәрләрен яисә» сүзләренә алмаштырырга;

14 пунктта «эшләр» сүзен «әсәрләрен яисә эшләрен» сүзләренә алмаштырырга, «ул» сүзен «алар» сүзенә алмаштырырга;

15 пунктта:

беренче абзацта «эшләр» сүзен «әсәрләр яисә эшләр» сүзләренә алмаштырырга, «тапшыралар» сүзенә кадәр «түбәндәге материалларны» сүзләрен өстәргә;

«а» пунктчасында «эшләр» сүзен «әсәрләр яисә эшләр» сүзләренә алмаштырырга;

«б» пунктчасында «тәкъдим ителгән эш» сүзләрен «әсәрләр яисә эшләр» сүзләренә алмаштырырга;

«г» пунктчасында «эшләр» сүзен «әсәрләр яисә эшләр» сүзләренә алмаштырырга;

«д» пунктчасында «эшләр» сүзен «әсәрләр яисә эшләр» сүзләренә алмаштырырга;

сигезенче абзацта «әсәрләрен һәм» сүзләрен «әсәрләрен яисә» сүзләренә алмаштырырга;

16 пунктта «Өстәмә материаллар» сүзләрен «utalents.ru сайты аша тутырыла алмый торган материаллар,» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган М.Җәлил исемендәге Республика премиясен бирү комитеты турындагы нигезләмәдә:

2 пунктның дүртенче абзацында «конкурс әсәрләре» сүзләрен «әсәрләр яисә эшләр» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге редакциядә $3^1$ пункт өстәргә:

«$3^1$. Комитет әгъзасы М.Җәлил исемендәге Республика премиясе йомгаклары белән турыдан-туры яисә читләтеп кызыксына торган яисә Комитет эшендә Комитет әгъзасының катнашуына йогынты ясый алырлык башка хәлләр булган очракта, ул бу хакта М.Җәлил исемендәге Республика премиясенә тәкъдим ителгән әсәрләрне яисә эшләрне карый башлаганчы ук Комитетка язма рәвештә хәбәр итәргә тиеш. Бу чакта Комитетның мондый әгъзасы тавышы Комитет утырышларының һәм карарлар кабул итүнең хокуклылыгын билгеләгәндә исәпкә алынмый.»;

5 пунктның икенче абзацында «һәр эшне» сүзләрен «һәр әсәрне яисә эшне» сүзләренә алмаштырырга;

6 пунктта «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты раславына» сүзләреннән соң «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «М.Җәлил исемендәге Республика премиясе комитеты турында» 1997 ел, 27 февраль, 175 нче карары белән расланган М.Җәлил исемендәге Республика премиясе турында нигезләмәнең 74 пунктында билгеләнгән вакытта» сүзләрен өстәргә, «(һәр ике ел)» сүзләреннән соң «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «М.Җәлил исемендәге Республика премиясе комитеты турында» 1997 ел, 27 февраль, 175 нче карары белән расланган М.Җәлил исемендәге Республика премиясе турында нигезләмәнең 74 пунктында билгеләнгән вакытта» сүзләрен өстәргә;

7 пунктта «Өстәмә материаллар» сүзләрен «utalents.ru сайты аша тутырыла алмый торган материаллар,» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган М.Җәлил исемендәге Республика премиясен бирү комитеты составында:

Сабирова Айгөл Азат кызы вазыйфасы исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министры урынбасары, Комитет секретаре».

2. Әлеге карар 2025 елның 1 маеннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин